**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА**
**Алькеевского**
**муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әлки**
**муниципаль районы**
**БАШЛЫГЫ**

Адрес: 422870, РТ, с.Базарные Матаки, ул. Крайнова, 58
факс: 8 (84346) 2-17-57

Адресы: 422870, РТ, Базарлы Матак авылы, Крайнов ур.58
тел: 8 (84346) 2-10-48

45№ 2014 елның 27 октябре

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ
# КАРАР

Әлки муниципаль районы Башлыгының 2010 елның 26 февралендәге «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү һәм коткару хезмәтен (гражданнар оборонасы хезмәтен)булдыру турында» 7 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Әлки муниципаль районы Башлыгы КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 26 февралендәге «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 6 октябрендәге «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 гыйнварындагы «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү һәм коткару хезмәтләрен (гражданнар оборонасы хезмәтләрен) оештыру турында» 6 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында» 716 номерлы карары нигезендә Әлки муниципаль районы Башлыгының 2010 елның 26 февралендәге «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү һәм коткару хезмәтен (гражданнар оборонасы хезмәтен)булдыру турында» 7 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында коткару хезмәтләрен (гражданнар оборонасы хезмәтләрен) формалаштыру һәм күрсәтелгән карар белән расланган эшчәнлек алып бару тәртибендә:

111 бүлектә:

1 пунктның бишенче абзацында «гражданнар оборонасы хезмәте» сүзләреннән соң «һәм гражданнар оборонасы гамәлләрен башкаруны тәэмин итү буенча штаттан тыш формированиеләр» сүзләрен өстәргә;

2 пунктта:

2.5 пунктчасының икенче абзацында «штаттан тыш авария-коткару формированиеләре» сүзләреннән соң «һәм гражданнар оборонасы гамәлләрен үтәүне тәэмин итү буенча штаттан тыш формированиеләр» сүзләрен өстәргә;

2.10 пунктчасының бишенче абзацында «штаттан тыш авария-коткару формированиеләре» сүзләреннән соң «һәм гражданнар оборонасы гамәлләрен үтәүне тәэмин итү буенча штаттан тыш формированиеләр» сүзләрен өстәргә;

V бүлектә:

1 пунктта «штаттагы һәм штаттан тыш авария-коткару формированиеләре» сүзләрен «авария-коткару формированиеләре, штаттан тыш оешмалар тарафыннан гражданнар оборонасы гамәлләрен башкаруны тәэмин итү буенча чаралар башкаруны тәэмин итү» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«6. Граждан оборонасы чараларын һәрьяклап тәэмин итү өчен гражданнар оборонасы хезмәте:

авария-коткару формированиеләрен, хезмәт эшчәнлеге профиленә туры килә торган гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү буенча штаттан тыш формированиеләрне җәлеп итәләр;

гражданнар оборонасы бурычларын хәл итү өчен җәлеп ителә торган хезмәтләр һәм оешмалар составына керүче формированиеләрне исәпкә алуны оештыралар.

Граждан оборонасы хезмәтләре тарафыннан җәлеп ителә торган гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү буенча авария-коткару формированиеләренең һәм штаттан тыш формированиеләрнең гомуми саны һәм аларның саны

тыныч һәм хәрби чорда хезмәт тарафыннан хәл ителә торган бурычларның характеры һәм күләме, җирле шартлар үзенчәлекләрен исәпкә алып, кешеләр ресурсларының һәм матди чараларның булуы белән билгеләнә..»;

күрсәтелгән карар белән расланган Әлки муниципаль районы граждан оборонасы чараларын тәэмин итү турында нигезләмәнең 9 пунктындагы икенче абзацында һәм 18 пунктындагы өченче абзацында «авария-коткару формированиеләре» сүзләреннән соң «, гражданнар оборонасы буенча чаралар үтәлешен тәэмин итү буенча штаттан тыш формированиеләр» сүзләрен өстәргә;

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү турындагы нигезләмәдә оешмалар исемендә булган үзгәрешләргә бәйле рәвештә «Базарлы Матак үзәк район хастаханәсе» МБУЗ - «Базарлы Матак үзәк район хастаханәсе» ДАССУ, «Малофеев» ИП - «Әлки коммуналь челтәрләре» ҖЧҖ, «Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Әлки муниципаль районы буенча идарәсе» - «Әлки муниципаль районы янгын саклау гарнизоны» исеменә алыштырырга.

2. Кертелгән үзгәрешләр белән Нигезләмәне расларга:

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында коткару хезмәтләрен (гражданнар оборонасы хезмәтләрен) төзү һәм аларның эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибе;

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының коткару хезмәтләре (гражданнар оборонасы хезмәтләре) структурасын;

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү турында нигезләмә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны (Әлки муниципаль районы Башкарма комитетына (Никошин А.Ф.) һәм Әлки муниципаль районы янгын саклау гарнизонына (Шалдымов В.В.) йөкләргә.

Әлки муниципаль районы Башлыгы: Ф.М. Дәүләтшин

Дәүләтшин Р.Г.
2-02-04